# Тарих хәтере



## Харрасова Кәүсәрия Фәтхетдин кызы

1948 нче елның 17 нче сентябрендә Мөслим районының Иске Карамалы авылында хезмәткәр гаиләсендә дөньяга килгән.

1968 нче елда Минзәлә педагогия училищесын тәмамлаганнан соң, үзе укыган Күбәк урта мәктәбенең башлангыч сыйныф укучыларын укыта башлый. 1977 нче елда Казан дәүләт университеты тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый һәм татар теле, әдәбияты дәресләре алып бара. Әдәбият-иҗат, мандолина түгәрәкләрен җитәкли. 1985-1987 нче елларда тәрбия эшләре буенча директор урынбасары вазифасын алып бара.

1989 нчы елда, гаилә хәле буенча, Зәй районы Бигеш авылына күчеп килә. Бер елдан соң Кама Аланы эшчеләр бистәсенә килә һәм хәзерге көнгәчә шунда яши.

2006 нчы елда “Татар теленнән кагыйдәләр җыентыгы” бастыра.

Педагогик хезмәтен бәяләп, 2000 нче елда ТР Мәгариф министрлыгы “Мәгарифтә казанышлары өчен” күкрәк билгесе беләен бүләкләнә.

2005 нче елда РФ Фән һәм Мәгариф министрлыгының Мактау грамотасына, 2006 нчы елда “РФ ның иң яхшы укытучылары” бәйгесендә грамотага һәм Президент грантына лаек була.

Хәзерге көндә лаеклы ялда. 2016 нчы елда “Күңел гөлләре” исемле беренче шигырь җыентыгы басылып чыкты.

Күңел гөлләремне бүләк итәм -  
Чәчәкләрдә мине танырсыз.  
Таҗларына тездем хисләремне,  
Йөрәгемне шуннан аңларсыз.



## Солтанов Рушат Җәүдәт улы

Мөслим районы Яңа Карамалы авылында 1956 нчы елның 26 нчы сентябрендә дөньяга килә. Күбәк урта мәктәбендә белем ала. Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлаганнан соң, Күбәк урта мәктәбендә укыта, 1983 – 1988 нче елларда Октябрь сигезьеллык мәктәбендә директор вазифасын башкара. 1988 нче елда Мөслим районы партия комитетында инструктор вазифасында эшли башлый. Яшь белгечнең тырыш хезмәтен күреп, аңа район мәгариф бүлеген җитәкләүне тапшыралар.

1998 нче елда Рушат Җәүдәт улын Мөслим районы хакимияте башлыгының социаль мәсьәләләр һәм мәдәни үсеш буенча урынбасары итеп билгелиләр.

Рушат Җәүдәт улының тырыш эшчәнлеге нәтиҗәсендә районыбызның социаль-мәдәни өлкәсе зур үсеш-үзгәрешләр кичерде. Яшь педагоглар ассоциациясе төзелү, милли фольклор ансамбльләре һәм халык театрларының эшчәнлеге яңартылу, районкүләм спорт ярышларының, спартакиадаларның оешкан тостә үтүе һ.б. – Рушат Солтановның зур хезмәте нәтиҗәсе.

Рушат Җәүдәт улы — Россиянең Халык мәгарифе отличнигы. Күп кенә Мактау кәгазьләренә, Татарстан Президентының Рәхмәт хатына, “Иң яхшы муниципаль хезмәткәр” исеменә лаек булды. 2015 нче елда аңа Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре исеме бирелде.



# Низамова Роза Нәгыйм кызы

1947 нче елда Әмәкәй авылында туа. Күбәк урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт мәдәният институтында укый. Мөслимдәге үзәкләштерелгән китапханәдә эшли. Мөслим урта мәктәбендә озак еллар татар теле һәм әдәбияты укыта.Укучылар белән драмтүгәрәк оештыра. Күп кенә конкурсларда катнашып, лауреат исеменә лаек була. Ул районда нәфис сүз остасы буларак танылу алды. Татарстанның атказанган укытучысы. Соңгы елларда нәфис чигү белән шөгыльләнә һәм күргәзмәләр оештыра.



# Әмиров Касыйм Зәки улы

1963 нче елның 20 октябрендә, Мөслим районы Иске Вәрәш авылда туган.Ул хезмәт сөючән, тәртипле гаиләдә туып үсә. Касыймга кул осталыгы әтисеннән күчсә, ә төгәл фәннәргә мәхәббәт, район финанс бүлегендә бухгалтер булып эшләгән әнисеннән күчкәндер.


Касыйм Зәкиевич мәктәптә бик яхшы укый. Тырыш укучы, Мөслим урта мәктәбен уңышлы тәмамлаганнан соң, Алабуга педагогия институтының физика-математика факультетына укырга керә. 1986 нчы елда институтнытәмамлап туган ягына кайткач, аны Күбәк урта мәктәбенә физика, математика укытучысы итеп билгелиләр. Ул вакытта мәктәп директоры Вәлиев Зәйнак Вәзиевич, беренче көнне үк Касыйм абыйны үз бүлмәсенә чакырып кертә һәм физика, математика, астрономия, хезмәт, сызым, рәсем, музыка фәннәрен йөкли. Беренче чыныгуны нәкъ шушы коллективта ала да инде Касыйм абый. Бүгенге көндә дә ул үзен профессиональ осталыкка өйрәткән мәктәп директоры Валиев Зәйнак Вәҗи улын, Сәрия һәм Марсель Юнысовларны җылы хисләр белән искә ала.

Педагогик яктан җитлеккән, тәҗрибә туплаган белгеч, ниһаять, 1990 нчы елда канат чыгарган мәктәбенә кайта һәм бүгенге көнгә кадәр ул хезмәт тәрбиясе бирү һәм сызым укытучысы буларак бөтен тырышлыгын биреп эшләгән белгеч. Хезмәткә өйрәтү дәресләре дә математика кебек үк төгәллек, камиллек таләп итә.

Касыйм Зәкиевич эшләү дәверендә үзен эзләнүчән, укыту методикасын яхшы белә торган, таләпчән педагог икәнен таныткан укытучы. Балаларга тәпле белем бирергә тырышу, эзләнү, яңалыкка, фәннилеккә омтылу билгеле эзсез калмый. 1990 нчы елдан алып бүгенге көнгә кадәр аның укучылары технология һәм сызым фәннәре буенча олимпиадаларда һәр елны призлы урыннар алып киләләр.

Мәктәптә үткәрелә торган бер генә чара да Касыйм абыйсыз үтми. Өздереп баянда уйнаган абыебыз һәр кичәнең, һәр концертның үзәгендә.

# Биктимеров Расил  Кашафетдин улы



1967 нче  елның 13 июлендә Мөслим районы Иске Карамалы авылында 5 балалы колхозчы гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килгән. Балалар бакчасында тәрбияләнгән. 1974-1984 нче елларда Күбәк урта мәктәбендә белем ала. Бирелә укыган чорда октябрят, пионер, комсомол сафларында, мәктәп тормышында, җәмагать эшләрендә актив катнаша. Рәсем ясау осталыгына ия була Расил,  мәктәпне 4-5 билгеләренә тәмамлый.

Мәктәпне тәмамлаганнан соң, сыйныфлары  белән берлектә, авыл хуҗалыгында эшкә кала егет, Куйбышев исемендәге күмәк хуҗалыкта тракторист булып эшли.

Расил Кашафетдинович 1985 елның ноябрендә Совет армия сафларына чакырыла, ике ел Владивосток шәһәрендә хезмәт итә.

1988 нче  елның гыйнвареннән Куйбышев исемендәге колхоз комсомол оешмасын җитәкли, авыл яшьләренең җирлектә экономик һәм социаль тормышта актив катнашуларын булдыруга ирешә. 1989 нче елда Советлар Союзы Коммунистлар партиясе сафларына керә.

Шул ук елны Күбәк авылы кызы Хасаншина Әнисә Гафурян кызы белән гаилә коралар.

1990 нче елның сентябреннән Күбәк урта мәктәбенә чакырыла. Рәсем, сызым һәм хезмәт укытучысы вазыйфалары йөкләнә.  Расил Кашафетдинович балаларны яратуы, эшенә җаваплы каравы белән аерылып тора.  1993 нче  елда Яр Чаллы педагогик институтының рәсем һәм сызым  сәнгате юнәлеше буенча укырга керә. Ләкин гаилә хәле буенча укудан китәргә туры килә Расил Кашафетдиновичка.

1999 нче  елда мәктәптә, 1985 нче елда шифаханәдә кочегар, 1998-1999 нчы елларда Алга ПМК-13 оешмасында эшли.

Кызганычка каршы,  1999 нче  елның ноябрь аенда  вафат була.



# Нурлыгаянов Наил Назиф улы

Нурлыгаянов Наил 1970 нче елның 28 нче августында, Сарман районы Саклаубаш авылында дөньяга килгән. Юллама белән эшкә җибәрелгән əти-əнисе белән туган якларына - Мөслим районы Иске Карамалы авылына Наил кечкенə чагында үк кире кайталар.Ул бик тырыш, тəртипле гаилəдə үсə. Наил Назифович мəктəптə иң яхшы укучы балаларның берсе була, Күбəк урта мəктəбен алтын медальгə тəмамлый. 1987 нче елда Мəскəү инженерия институтының авыл хуҗалыгы механизациясе факультетына укырга керə. 1992 нчы елда институтны тəмамлап туган ягына кайткач, аны Мөслим районы “Калмыя” бүлегенə колхоз механигы итеп эшкə билгелилəр.

1995 нче елда Наил Назифовичны, үзе тəмамлаган Күбəк урта мəктəбенə эшкə чакыралар, информатика, сызым, хезмəт, сəнгать фəннəрен укытуны йөклилəр. Мəктəптə беренче көннəн үк яшь белгеч (компьютер чыга башлаган вакытлар) 11 персональ компьютер кабинетын, хезмəт остаханəсен житəкли, укучыларга ныклы белем бирə.

2001 нче елда Наил Назифович янə Әлмəт шəһəре нефть институтына укырга керə, һəм шул белгечлек буенча Жəлил шəһəренə оператор булып эшкə күченə.

2008 нче елдан бүгенге көнгə хəтле “Тюменьпромгеофизика”учреждениесендə геофизик вазыйфасын башкара.

Наил Назифович эзлəнүчəн, максатчан, һəрвакыт үзе өстендə эшли торган торган шəхес. Күп кенə яңа компьютер программаларын үзлегеннəн үзлəштерə, яңалыкка омтыла.

Бүгенге көндə тормыш иптəше Фирая белəн алмадай 3 кыз үстерəлəр. Ике кызлары Казан шəһəренең югары уку йортларында белем алалар.

## Халиуллина Лилия Мирзанур кызы



1970 нче елның 6 нчы ноябрендә ТР Мөслим районы Метрәй авылында колхозчы гаиләсендә туган. Гаиләсндә 6 баланың дүртенчесе. 1977 нче елда Метрәй урта мәктәбенә укырга кергән. 1987 нче елны урта мәктәпне яхшы билгеләргә тәмамлап, Яр Чаллы дәүләт педагогия институтының “Башлангыч сыйныфлар укытучысы” бүлегенә укырга кергән. 1991 нче елда институтны тәмамлап, Мөслим районына эшкә кайтып, Яңа Карамалы башлангыч мәктәбенә укытучы итеп билгеләнгән. 2010 нчы елда “Башлангыч сыйныфларда инглиз теле укытучысы” дигән өстәмә югары белем алган.

Башлангыч мәктәптә эшләү дәверендә Яңа Карамалы мәктәбе районда алдынгылардан саналды, яңа уку елына әзерлек буенча берничә ел рәттән алдынгы урыннарны алдык, - дип искә ала Лилия Мирзануровна.

Балалар бакчасы белән берлектә төрле бәйрәмнәр, кичәләр үткәрәләр: гаилә бәйрәме, Яңа ел, 8 Март, Сабантуйлар һәркемнең исендә калырлык.

Күрше-тирә авыллардагы башлангыч мәктәп укытучылары һәм укучылары белән дә тыгыз элемтәдә торып, Октябрь, Дусай башлангыч мәктәпләре белән кулга-кул тотынышып хезмәттәшлек иткәннәр.

Лилия Мирзануровна укучылары белем дәрәҗәсенә килгәндә сынатмаганнар, алар төрле инша язу, шигырь сөйләү конкурсларында, бөтенроссия дистанцион олимпиадаларында катнашып, призлы урыннар яуладылар.

Район күләмендә үткәрелгән семинарларда актив катнашып, укытучыларга ачык дәресләр, сыйныфтан тыш чаралар күрсәтеп, төрле семинарларда чыгышлар ясыйлар.

Укучылары Күбәк урта мәктәбенә киткәч тә югалып калмыйлар. Башлангыч мәктәптә алган белемнәрен тагын да тирәнәйтеп, югары уңышларга ирешәләр.



## Халикова Фидалия Дамир кызы

1968 нче елнын 2 сентябрендә Мөслим районы Иске Карамалы авылында туа. Бар эшкә дә кулы ятып торучы, хезмәт яратучы әтисе Дамир абый, җавапчыл, тырыш әнисе Хәния апа кызлары Фидалиядә дә үзләре кебек сыйфатлар тәрбиялиләр. Фидалия 1975 нче елның 1 сентябрендә Күбәк урта мәктәбенә укырга керә. 1985 нче елда урта мәктәпне яхшы билгеләргә генә тәмамлаган кыз, укытучы һөнәрен үзләштерү максаты белән, Казан шәһәренә юл ала. 1985-1990 нче елларда Казан дәүләт педагогия институтында укый. Хезмәт юлын 1990 нчы елның 1 сентябрендә Күбәк урта мәктәбендә химия һәм биология укытучысы буларак башлап җибәрә. 1996 нчы елга яшь, матур, тырыш кыз Күбәк урта мәктәбендә балаларга табигать фәннәренең асылын өйрәнергә булыша, туган як табигатенә мәхәббәт тәрбияли.

Хәзерге көндә Халикова Фидалия Дамир кызы Казанда яши. Ул «IT-лицей КФУ»ның югары категорияле химия укытучысы, педагогик фәннәр кандидаты, КФУның химик фәннәр кафедрасы доценты, хезмәт юлында зур уңышларга ирешкән мөгаллимә.



## Госсамова Фәридә Әсгать кызы

Туган җире – Мөслим районы Баек авылы. Алабуга дәүләт педагогия институтын тәмамлап, 1985елда Октябрь сигезьеллык мәктәбенә эшкә җибәрелә. 1987 елда хезмәт юлын Күбәк урта мәктәбендә башлангыч сыйныфлар укытучысы булып дәвам итә. Фәридә Әсгать кызы бар күңелен, тырышлыгын балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлап эшли. Эшне җиренә җиткереп эшләвен күреп, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары итеп билгелиләр. Башлангыч сыйныфларда укыту белән бергә, бу эшне дә яратып башкара ул.

1996 нче елда гаиләсе белән Чаллы шәһәренә күченеп китәләр.

Бугенге көндә Фәридә Әсгать кызы лаеклы ялда. Кайда гына эшләсә дә аның хезмәте югары бәяләнә. Ул-беренче категорияле укытучы, бик күп мактау кәгазьләренә ия, "Мәгарифтәге казанышлары өчен" күкрәк билгесе белән бүләкләнә.



## Муллагалиева (Шигапова) Алия Альберт кызы

2000 нче елны Алабуга Дэулэт педагогия институтын тәмамлап, Яр Чаллы шәһәренең 52 нче мәктәбенә инглиз теле укытырга эшкэ урнаша. Анда 4 ел эшләгәннән соң, узенең туган авылы Күбәк урта мәктәбенә эшкә кайта. Бер ел укыткач, гаилә хәле буенча күченеп китә.



## Харисова Ләйсән Мирдәвис кызы

1975 нче елның 19 нчы ноябрендә Мөслим районы Яңа Карамалы авылында туа. Башлангыч белемне Күбәк урта мәктәбендә ала.

1993 нче елда Алабуга дәүләт педагогия институтының филология бүлегенә укырга керә. 1998 нче елда татар теле, әдәбияты һәм чит телләр укытучысы белгечлеге буенча кулына диплом ала.

Күбәк урта мәктәбенә немец теле укытучысы булып эшкә урнаша. Укыту белән берлектә, аңа класс җитәкчелеге бирелә. 10 нчы класс кызлары, егетләре була ул. Алар белән кулга - кул тотынышып кызыклы, күңелле эш башлана.

Бу эшкә кереп китәргә ярдәм итүче Ләйсинә Расиловна, Рәзимә, Сәрия Мирзануровна апаларны ихтирам белән искә ала Ләйсән.

2001 нче елда Мөслим районы үзәгендә урнашкан "Карлыгач" балалар бакчасына тәрбияче булып эшкә күчә. Шул ук вакытта өстәмә педагог-психолог белеме алып, психолог эшен дә алып бара.

2014 нче елда Ләйсән Мирдәвис кызы Мөслим үзәгендә урнашкан "Миләшкәй" балалар бакчасына мөдир итеп билгеләнә. Бүгенге көнгә кадәр шунда хезмәт куя.



## Гәрәева Алсу Флүр кызы

1988 нче елның 8 апрелендә туган. Күбәк урта мәктәбен тәмамлап, 2003 нче елда Минзәлә педагогия көллиятенә укырга керә, уку йортын уңышлы тәмамлаганнан соң, 2008 нче елда туган мәктәбендә эшли башлый. 2012 нче елда Яр Чаллы педагогия институтын тәмамлый. Заман таләпләренә туры килер өчен даими эзләнергә, өйрәнергә кирәк, шул максаттан Алсу Флүровна һәрдаим үз белемен күтәрү өстендә эшли.

Тырышлыгының нәтиҗәсе дә күренә, ел саен диярлек Бөтенрәсәй укучылар олимпиадасының муниципаль этабында призерлары бар. Мәктәптән тыш эшләр үзәге үткәргән конкурсларда даими катнаша, укучылары белән ел саен гран-при һәм призлы урыннар яулый. Республикакүләм конференцияләрдә катнашып, дипломант булып кайталар. Алсу Флүровна “Ел укуытучысы-2016” бәйгесенең муниципаль этабында катнашып, 2 нче урын яулый.

Күбәк урта мәктәбендә 2020 нче елга кадәр эшләде.



## Зиазова Алсу Фәвәрис кызы

1990 нчы елның 17 нче сентябрендә Мөслим районы Яңа Сәфәр авылында дөньяга килә. Башлангыч белемне үз авылларында ала. Төп белемне 6 чакырым ераклыкта урнашкан Баек урта мәктәбендә ала.

9 нчы сыйныфны тәмамлагач, 2014 нче елда, Түбән Кама педагогия училищесының башлангыч сыйныфлар укытучысы бүлегенә укырга керә. Биредә 4 ел белем ала. 2009 нчы елда, училищены уңышлы гына тәмамлап, Алабуга педагогия университетына педагог-психолог белгечлеге буенча читтән торып укырга керә.

Түбән Кама педагогия училищесын тәмамлау белән Мөслим районы Иске Чакмак башлангыч мәктәбенә башлангыч сыйныфлар укытучысы итеп билгеләнә. 2010-2015 нче елда Күбәк урта гомуми белем бирү мәктәбендә, 2015-2020 нче елда Г.Тукай исемендәге Мөслим урта гомуми белем бирү мәктәбендә башлангыч сыйныфлар укытучысы булып эшли. 2020 нче елдан хезмәт юлын Мөслим лицеенда дәвам итә.



## Ханнанова Гөлназ Мисбах кызы

Мөслим районы Салавыз Мухан авылында колхозчылар гаиләсендә бишенче бала булып дөньяга килгән. 1985 нче елда Салавыз Мухан урта мәктәбенә кереп, 1995 нче елда уңышлы тәмамлый. 1995 – 2000 нче елларда Алабуга дәүләт педагогия институтының биология һәм авыл хуҗалыгы факультетында белем ала.

2000 нче елда Октябрь урта гомуми белем бирү мәктәбенә химия һәм биология укытучысы итеп билгеләнә. 2013 нче елга кадәр шул мәктәптә хезмәт итә.

2013-2014 нче елларда Әмәкәй мәктәбендә химия-биология укытучы булып, 2015- 2020 нче елларда Октябрь авылы “Ландыш” балалар бакчасы мөдире булып эшли.

2019-2020 нче елда Күбәк урта мәктәбендә химия – биология фәннәрен укыта.

Хәзерге вакытта Октябрь авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкара.



# Сабирова (Якупова) Эльвира Рафис кызы

2005 нче елда Күбәк урта мәктәбен көмеш медаль белән тәмамлаган. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты факультетына укырга керә. 2 ел укыгач, читтән торып уку бүлегенә күчеп, Күбәк урта мәктәбенә башлангыч сыйныфлар укытучысы булып эшкә кайта. Ә соңыннан татар теле һәм әдәбияты фәнен укытуга күчә. “Күбәк урта мәктәбендә үземне укыткан укытучыларымның ярдәмен тоеп, аңлашып, зур тәҗрибә туплап 3 ел хезмәт куйдым”, - дип уртаклаша Эльвира Рафис кызы. 2010 нче елда Актаныш районына кияүгә чыга. Актаныштa “Әтәчкәй” балалар бакчасында хезмәтен дәвам итә. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны рус теленә өйрәтүче белгеч булып балалар бакчасында эшли башлый.

Эшләгән дәвердә балалар бакчасында икетеллелеккә өйрәтү буенча уздырылган республикакүләм “Иң яхшы билингваль балалар бакчасы” бәйгесендә грант ота, район башлыгының Мактау грамотасына лаек була, “Ел тәрбиячесе-2019” республикакүләм бәйгесенең район этабында 1 урын ала.

Бүгенге көндә Актаныш районы 1 нче санлы “Умырзая” балалар бакчасының өлкән тәрбиячесе булып эшли. Актаныш районы балалар бакчаларында эшләүче тәрбиячеләрнең район методик берләшмәсен җитәкли.



## Галимова Наилә Исмәгыйль кызы

1961 нче елның 17 нче апрелендә Зәй районы Аксар авылында Талыйповлар гаиләсендә дөньяга килә.

1978 нче елда Югары Шепкә урта мәктәбен тамамлагач, Алабуга дәүләт педагогия институтына укырга керә.

1983 нче елда хезмәт юлын Зәй районы Федоровка авылында башлап җибәрә.

1987 нче елда, тормышка чыгу сәбәпле, Күбәк урта мәктәбенә килә. Наилә Исмәгыйловна география фәнен укыту белән бергә, директорның тәрбия эшләре буенча урынбасары вазифасын башкарды. Пионер вожагы Ләйсинә Расиловна белән алар бердәм булып, укучылар эшчәнлегенә яңача сулыш бирәләр. Тату җитәкчеләр башлангычында оештырылган һәр чара максатына ирешә. Район күләмендә катнашкан ярышлардан да җиңү яулап кайта алар.

Наилә үз профиле буенча укытуга күчә. Нәниләрне беренче сыйныфтан җитәкләп алып китә. 2003 нче елга кадәр башлангыч класслар укытучысы булып намуслы хезмәт куйды. Ул укучылары өчен таләпчән укытучы булу белән янәшә, ягымлы киңәшче дә, кайгыртучан апа да булды. Укучылар һәм ата-аналар аны нәкъ шул сыйфатлары өчен яраттылар да.

2002 нче елның февралендә хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнә.

2003 нче елда Яр Чаллы каласына күченеп китә.